**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2015 ел, 3 июнь

№ 399

г. Казань

Муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының мәгариф бүлекләре (идарәләре) җитәкчеләре һәм гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре вакантлы вазыйфаларын биләүгә кандидатлар сайлап алганда, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасында хезмәттәшлек регламентын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль законның 89 статьясындагы 2 өлеш нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарга теркәлгән Муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының мәгариф бүлекләре (идарәләре) җитәкчеләре һәм гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре вакантлы вазыйфаларын биләүгә кандидатлар сайлап алганда, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасында хезмәттәшлек регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы белән берлектә, әлеге карар үз көченә кергәннән соң, 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге арасында мәгариф өлкәсендә хезмәттәшлек системасын формалаштыру турында үрнәк килешү формасын эшләргә һәм расларга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының мәгариф бүлекләре (идарәләре) җитәкчеләре һәм гомуми белем бирү оешмалары директорлары

вакантлы вазыйфаларын биләү буенча эшне оештырганда, әлеге карар белән расланган Регламентка таянып эш итәргә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасында расланган форма нигезендә килешүләр төзергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\399.doc

Татарстан Республикасы Министлар Кабинетының 2015 ел, 3 июнь, 399 нчы карары белән расланды

Муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының мәгариф бүлекләре (идарәләре) җитәкчеләре һәм гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре вакантлы вазыйфаларын биләүгә кандидатлар сайлап алганда, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасында хезмәттәшлек
РЕГЛАМЕНТЫ

1. Әлеге Регламент муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының мәгариф бүлекләре (идарәләре) җитәкчеләре һәм гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре вакантлы вазыйфаларын югары профессиональ кадрлар белән биләү максатында эшләнде һәм муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының мәгариф бүлекләре (идарәләре) җитәкчеләре һәм гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре вакантлы вазыйфаларын (алга таба – идарә вазыйфалары) биләүгә кандидатлар сайлап алганда, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең хезмәттәшлек механизмын билгели.

2. Вакантлы идарә вазыйфаларын биләү, шул исәптән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан формалаштырыла торган Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә идарә кадрлары резервына (алга таба – кадрлар резервы) кертелгән затлар арасындагы гражданнар белән, гамәлдәге законнар нигезендә тормышка ашырыла.

3. Вакантлы идарә вазыйфасын биләү өчен кадрлар резервына кертелгән гражданнар турында белешмәләр алу максатында, тиешле муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты җитәкчесе, вакантлы вазыйфа барлыкка килгән көннән башлап, 3 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына вакантлы вазыйфа турында, шулай ук аны биләү өчен кирәкле белгечлеккә һәм квалификациягә карата таләпләр турында мәгълүматны үз эченә алган сорату юллый.

4. Кадрлар резервында кирәкле белгечлеккә һәм квалификациягә ия граждан булган очракта, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, сорату алган көннән соң, 3 эш көне эчендә әлеге гражданга вакантлы идарә вазыйфасы турында хәбәр итә.

Белдермә гражданның үзенә имзалау өчен бирелә яисә заказлы хат белән тапшыру турында хәбәр итеп яки адресат тарафыннан хатны алу көнен теркәүне тәэмин итүче башка элемтә һәм илтеп тапшыру чараларын кулланып юллана.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының кадрлар резервына кертелгән граждан, вакантлы идарә урыны булуы турында тәкъдим алган көннән соң, 5 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы адресына вакантлы идарә вазыйфасын биләүдә катнашуга язмача ризалык яки язмача баш тарту юллый.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының кадрлар резервына кертелгән гражданның билгеләнгән вакытта җавап тапшырмавы баш тарту буларак карала.

5. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының кадрлар резервында кирәкле белгечлеккә һәм квалификациягә ия берничә зат булган очракта, вакантлы идарә вазыйфасы булу турында тәкъдим барлык затларга да юллана.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, әлеге Регламент белән күздә тотылган барлык кирәкле процедураларны үтәгәннән соң, 3 эш көне эчендә муниципаль берәмлеккә гражданның җитәкче вазыйфа биләүдә катнашу карары турында мәгълүмат юллый.